| МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.06.2020 г.Казань № 435

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 10 июлендә 6752 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 19 октябрендәге 967 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 19 октябрендәге 967 номерлы «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр

күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләрне (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 12 февралендәге 89 номерлы боерыгында кертелгән үзгәрешләр белән) расларга.

Министр Э.А. Зарипова

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин
итү һәм социаль яклау
министрлыгының 2020 елның 18
июнендәге 435 номерлы
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының
2018 елның 19 октябрендәге 967 номерлы «Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.2 пунктның беренче абзацында «социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар» сүзләреннән соң «1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы «Коммерциясез оешмалар турында» Федераль законының 2 статьясындагы 22 пунктнын 1 пунктчасында каралган (алга таба - социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар, коммерциясез оешмалар)» сүзләрен өстәргә (әлеге абзацның таләпләре 2020 елның 15 сентябреннән гамәлдә);

1.4.1 пункттагы тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең башкарылуын контрольдә тоту өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр әлеге Регламентның белешмәле кушымтасында китерелгән.»;

1.4.3 пункттагы икенче абзацта «урнаштырыла торган» сүзләреннән соң «Министрлык сайтында, «Интернет» челтәрендә» сүзләрен өстәргә;

1.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актларның реквизитлары һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганаклары белән) Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.6 пунктта:

өченче абзацта «муниципаль районның (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә» сүзләрен «муниципаль районның шәһәр (авыл) җирлегендә яисә шәһәр округында» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацта «210-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2010 елның

27 июлендәге 210-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль законы (алга таба - 210-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив хокукый акт» графасында «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Нигезләмә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 22 августындагы 681 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган иҗтимагый хезмәт күрсәтү сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирүне оештыру турында нигезләмә» (алга таба - Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2018 № 681 карары белән расланган Нигезләмә)» сүзләренә алмаштырырга;

2.3 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының беренче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләргә» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы «Коммерциясез оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәт башкаручылар реестры турында» карары белән расланган Иҗтимагый юнәлешле коммерциясез оешманы иҗтимагый файдалы хезмәт башкаручы итеп тану турында карар кабул итү кагыйдәләренә» сүзләренә алмаштырырга;

2.4 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасындагы икенче абзацта «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы «Коммерциясез оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәт башкаручылар реестры турында» карары белән расланган Иҗтимагый юнәлешле коммерциясез оешманы иҗтимагый файдалы хезмәт башкаручы итеп тану турында карар кабул итү кагыйдәләре (алга таба - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2017 елның 26 гыйнварындагы 89 номерлы карары белән расланган Кагыйдәләр)» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләп атамасы» графасында «башка оешмалар» сүзләрен «дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалар» сүзләренә алмаштырырга;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасының икенче абзацында «44-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен «2013 елның 5 апрелендәге 44-ФЗ номерлы «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында» Федераль закон (алга таба - 44-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктның «Дәүләт хезмәтен яисә таләбен билгеләүче норматив акт» графасында «РФ Президентының 601 номерлы Указы» сүзләрен «Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы «Дәүләт

идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» сүзләренә алмаштырырга;

2.16 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасында «63-ФЗ номерлы Федераль закон» сүзләрен 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы «Электрон имза турында» Федераль законы (алга таба - 63-ФЗ номерлы Федераль закон)» сүзләренә алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.1.1 пунктындагы беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1.1. Социаль юнәлешле коммерциясез оешмалар тарафыннан социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә иҗтимагый файдалы хезмәт сыйфатының билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:»;

5 бүлекнең 5.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, аның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр шикаять белдерү хокукына ия.

Дәүләт хезмәте күрсәтелүгә бәйле рәвештә министр кабул иткән карарларга, гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаятьләрне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырырга мөмкин.»;

Регламентка 1 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта»;

Регламентка 3 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта»;

Регламентка 4 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта»;

Регламентка 5 нче кушымтаның нумерацияле баш исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр

күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта»;

Регламентка кушымтаны (белешмә) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Кушымта (белешмә)
Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә социаль юнәлешле коммерциясез оешма тарафыннан иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтү сыйфатын бәяләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына

Социаль юнәлешле
коммерциясез оешмалар тарафыннан
социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә иҗтимагый файдалы хезмәт сыйфатының
билгеләнгән критерийларга туры килүе турында бәяләмәләр бирү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтү өчен
җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш
тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | (843) 557-20-01 | mtsz@tatar.ru |
| Министр урынбасары | (843) 557-20-14 | Yuliya.Abdreeva@tatar.ru |
| Социаль хезмәт күрсәтү сыйфаты белән идарә итү бүлеге башлыгы | (843) 557-20-53 | Almaz.Abdullin@tatar.ru |

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш идарәсе башлыгы | (843) 264-77-29 | pisma@tatar.ru». |